

Мордовиядә 290 км артык автомобиль юлы ремонтлана һәм тозелә. Эшләр «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» милли проекты кысаларында алып барыла, дип хәбәр итә Мордовия Хокvмәтенен матбугат хезмәте.
Ике капиталь кvп таләп итvче объектны тозv дәвам итә: Мордовия башкаласында Строительная урамы буенча юлvткәргеч (Победа урамыннан Гожувская урамына кадәр) тимер юл белән Инсар елгасы аша һәм Рузаевка шәһәрен транспорт белән урап узу.
Кvпер корылмалары ремонтлана, шул исәптән Саранскинын Титов урамындагы һәм Дубенка районынын Чеберчинка елгасы аша кvперләр.
91,26 км озынлыктагы 32 автомобиль юлы участогы файдалануга тапшырылган. Шулай ук 1,645 млн кв. м. мәйданлы оске катламнарны җәю буенча эшләр башкарылган.
Тагы Темников районында «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» милли проекты кысаларында сонгы оч елда авыл юллары норматив хәлгә китерелгән. Темников - Барашево юлларынын 1,28 км озынлыктагы һәм Русское Караево авылыннан Темников - Жегалово автоюлына кадәр (4,1 км) участоклары капиталь ремонтланган.
Узган ел Митрялы авылы - Кәгазь фабрикасы - «Ковылкино, Краснослободск шәһәрләре - Ельники авылы - Темников шәһәре» (0,63 км) һәм Лесное Ардашево авылы - «Темников шәһәре – Барашево Бистәсе – Теньгушево авылы» (2,4 км) автомобиль юлларына ремонт ясалган.
Исегезгә тошерәбез, Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан 13 милли проект игълан ителде: «Демография», «Мәдәният», «Сәламәтлек саклау», «Мәгариф», «Торак һәм шәһәр мохите», «Экология», «Куркынычсыз сыйфатлы юллар», «Хезмәт житештерvчәнлеге һәм мәшгульлеккә ярдәм», «Фән һәм университетлар», «Цифрлы икътисад», «Кече һәм урта эшкуарлык», «Халыкара кооперация һәм экспорт», «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе»

**Н.ХӘЛИЛ**